ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№20 Кече Урыссу ав. 22 сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2017 елның 10 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты турында»гы 2 санлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге карарларны үз көчләрен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2017 елның 10 мартындагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмәне раслау хакында»гы 2 санлы карарын;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 июнендәге “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында”гы 9 санлы карарын;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында”гы 6 санлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев